**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының**
**"Шәһәр тибындагы Апас поселогы" муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

2020 ел, 17 февраль №1

**“Шәһәр тибындагы Апас поселогы”муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында**

"Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә **карар итәм:**

1.«Шәһәр тибындагы Апас поселогы » муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Апас муниципаль районының рәсми сайтында «Апас шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлеге бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**"Шәһәр тибындагы Апас поселогы "**
**муниципаль берәмлеге Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов**

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
"Шәһәр тибындагы Апас поселогы "
муниципаль берәмлеге Башлыгының
2020 елның 17 февралендәге
1 номерлы карары белән
расланган

**“Шәһәр тибындагы Апас поселогы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

1.Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм “Шәһәр тибындагы Апас поселогы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына (алга таба - җирле үзидарә органнарына) гражданнар мөрәҗәгатьләрен (алга таба - мөрәҗәгатьләрне) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләренә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында гамәлгә ашырыла.

3.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә торган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау өчен җаваплы вазыйфаи зат (алга таба - вазыйфаи зат) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү вакыты-елга бер тапкыр: ел үткәннән соң билгеләнә.

5.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тиешле чорга кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып, шул исәптән язма рәвештә, электрон хәбәрләр рәвешендә, шулай ук Интернет-кабул итү, гражданнарны шәхси кабул итү барышында һәм телефон аша кабул ителә.

6.Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча, хисап чорыннан соң килүче айның 10 конена кадәр вазифаи зат аналитик белешмә төзи.

7.Аналитик белешмә үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

- кергән, адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр саны турында;
- гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;
- шәхси кабул ителгән гражданнар саны турында;
- гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында;
- мөрәҗәгатьләр тематикасы турында;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат (булганда).

8.Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең аналитик белешмәсе, шулай ук билгесез затлар мәнфәгатьләренә кагылышлы иң актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмалар Апас муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Шәһәр тибындагы Апас поселогы” муниципаль берәмлеге бүлегендә урнаштырыла.